БИШЕНЧЕ ЧАКЫРЫЛЫШ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БИЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАРЫ

2026 ел, 25 август № 21

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Биеш авыл җирлеге Советы депутаты статусы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы "Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Биеш авыл җирлеге Советы карар итте:

1. "Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Биеш авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында Нигезләмә хакында" Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Биеш авыл җирлеге Советының 2021 елның 9 августындагы 50 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Биеш авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 нче маддәнең 3 нче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«3. Совет депутатына үз вәкаләтләрен даими булмаган нигездә гамәлгә ашыру өчен эш бирүче тарафыннан эш урынын (вазыйфасын) саклап калып эшләүдән азат ителү, дәвамлылыгы Татарстан Республикасы законы нигезендә җирлек уставы белән билгеләнә торган һәм аена ике эш көненнән кимрәк һәм алты эш көненнән артыграк була алмаган чорга гарантияләнә.»;

2) 2 мәддәнең 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Депутатның вәкаләтләре ул сайланган көннән башлана һәм яңа чакырылыш Советының хокуклы составта беренче утырышын уздырган көннән туктатыла.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында, мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Апас муниципаль районы
Биеш авыл җирлеге Башлыгы Р.А. Валиев